РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«16» 09 2013ел. №512

Мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыручы белем бирү оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чараларын күрсәтү турында

Мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыручы белем бирү оешмаларына йөрүче балалары булган гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2014 елның 1 гыйнварыннан мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен (алга таба - компенсацион түләүләр) билгеләргә.
2. Кушымта итеп бирелгән компенсацион түләүләр Тәртибен (алга таба - Тәртип) расларга.
3. Ютазы муниципаль районының финанс-бюджет палатасына 2014 елдан башлап, Чираттагы финанс елына һәм план чорына Ютазы районы бюджетын формалаштырганда компенсацион түләүләр бирү өчен кирәкле чараларны күздә тотарга кирәк
4. 2014 елның 1 гыйнварыннан компенсация түләүләрен алу хокукын рәсмиләштерү 2013 елның 1 октябреннән гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Р. Ф. Вәдигуллинга йөкләргә.

Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе А. Н. Подовалов

Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән расланды

«__» _______ 2013ел № __

Мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыручы белем бирү оешмаларына йөрүче балалары булган гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү ТӘРТИБЕ

## 1.Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләрен (алга таба - компенсация) һәм түләү тәртибен, шартларын билгели.

1.2. Компенсация законлы вәкилгә (ата - анага, уллыкка алучыга, опекунга) яки аның вәкаләтле затына, белем бирү оешмасы белән килешү төзегән һәм баланы мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программасын гамәлгә ашыручы тиешле мәгариф оешмасына (алга таба-мөрәҗәгать итүче) караган өчен ата-ана түләве керткән, гаиләнең җан башына уртача керемен исәпкә алып билгеләнә һәм түләнә.

1.3. Керемнәрне компенсацияләүне алу хокукын билгеләгәндә һәм гаиләнең җан башына уртача керемен исәпләү «Гаиләнең һәм ялгыз яшәүче гражданның керемен аз керемлеләр дип тану һәм аларга дәүләт социаль ярдәме күрсәтү өчен исәпкә алу һәм аларның җан башына уртача керемен исәпләү тәртибе турында " 2003 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

1.4. Компенсация күләмен билгеләгәндә гаилә составында исәпкә алына:

18 яшькә җитмәгән һәм иждевениедә торган балалары, шул исәптән хастаханәләрдә, балалар шифаханәләрендә дәваланучы балалары, шулай ук интернат-мәктәпләрдә тәрбияләнгән өчен ата-аналары алар өчен өлешчә акча керткән балалар.

18-23 яшьлек балалар (никахта тормаучы), көндезге форма буенча укучы, шул исәптән дәүләтнеке булмаган уку учреждениеләрендә белем алучы балалар, ата-аналары белән бергә яшәү-яшәмәү фактына карамастан;

гаиләдә яшәүче үги малайлар һәм үги кызлар, әгәр аларбашка әти-әнинең гаиләсендә исәпкә алынмаган булса;

гражданнар гаиләләрендә опекага алынган балалар;
тәрбиягә бала алган гаиләләрдә тәрбияләнүче балалар.

1.5. Гаилә составында дип түбәндәге балалар саналмый:
балалары мөнәсәбәтендә ата - ана (тулы булмаган гаиләдә ата яки ана) хокуктан мәхрүм ителгән булса;
тулысынча дәүләт тәэминлегендә торучы балалар.

1.6. Компенсация күләме формула буенча исәпләнә:
ДК= Ф х (100-МДД) - К , монда:
ДК - компенсация күләме;
Ф - мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыручы мәгариф оешмасында баланы караган һәм тәрбияләгән өчен алына торган ата-ана түләвенең күләме;
МДД - мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыручы мәгариф оешмасында баланы караган һәм тәрбияләгән өчен таблицага туры китереп билгеләнгән ата-ана түләвенә гражданнарның мөмкин булган чыгымнары;
К - Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыручы мәгариф оешмаларында баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләвенең бер өлешен компенсацияләү турында» 2007 елның 18 гыйнвар №9 карары белән билгеләнгән тәртиптә исәпләнгән мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыручы мәгариф оешмаларында баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләвенең бер өлешен компенсацияләү күләме.

Таблица

Мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыручы мәгариф оешмасында баланы караган һәм тәрбияләгән өчен гражданнарның ата-ана түләвен түләү чыгымнарының максималь рөхсәт ителгән өлеше

| Бер гаилә әгъзасына табыш күләме | Ата-ана түләвен түләүгә гражданнар чыгымнарының максималь рөхсәт ителгән өлеше (%) | | |
|---|---|---|---|
| | 1 балага | 2 балага | 3 балага |
| 10 000 сумга кадәр | 60 | 38 | 23 |
| 10 001 сумнан башлап 15 000 сумга кадәр | 70 | 43 | 36 |
| 15 001 сумнан башлап 20 000 сумга кадәр | 80 | 53 | 53 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 20 000 сумнан артык | 100 | 100 | 100 |

2. Компенсация билгеләү һәм түләү тәртибе

2.1. Компенсация алу өчен мөрәҗәгать итүче яшәү урыны буенча (тору урыны буенча мөрәҗәгать итүченең теркәлмәгән очракта) муниципаль райондагы компенсация түләүгә вәкаләтле органга (алга таба – вәкаләтле орган) түбәндәге документларны тапшыра:

а) компенсация билгеләү турында гариза;

б) гаиләнең һәр әгъзасының өстәмә компенсация бирү турында гариза бирү аеннан өч ай элек булган керемнәре турында документлар;

с) компенсация билгеләнә торган баланың туу турындагы таныклыгының күчермәсе, аңа (күчермәсе нотариуста расланмаган булса, төп нөсхәсен күрсәтеп);

d) гариза бирүче әтисе яки әнисе (законлы вәкиле) булган башка балаларның туу турында таныклыкның күчермәләре (уллыкка алу) (күчермәсе нотариуста расланган булса). Опекадагы балага компенсация билгеләү өчен өстәмә рәвештә баланы опекага алу турында җирле үзидарә органнары карарыннан өземтә бирелә;

е) ышанычлы затлар өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә күчермәсе;

f) бала (балалар) мөнәсәбәтендә атаның яки ананың суд карары белән ата-ана хокукыннан мәхрүм ителгән очрагында;

g) тиешле мәгариф оешмасына баланы урнаштыру турында килешү күчермәсе;

h) мәгариф оешмасында баланы караган һәм тәрбияләгән өчен түләү квитанциясенең күчермәсен;

i) гариза бирүченең гаилә әгъзаларыннан яисә аларның законлы вәкилләреннән документ (ирекле формада):

j) аларның шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалык булу;

к) мөрәҗәгать итүченең шәхси мәгълүматларны органга яки оешмага тапшырганда аларның исеменнән эш итәргә вәкаләте.

Мөрәҗәгать итүче гариза белән мөрәҗәгать иткәндә, банк аша компенсация алганда, белем бирү оешмасы белән килешү төзегән затның кредит оешмасында шәхси счет номерын паспорт (аны алмаштыручы документ),күрсәтә.

Мөрәҗәгать иткән көнгә мөрәҗәгать итүче гаиләнең (ялгыз яшәүче гражданның) җан башына уртача керемен исәпкә алып билгеләнгән социаль ярдәм чараларын алучы булса, мөрәҗәгать итүче керемнәр турында белешмәләр бирү вазыйфасыннан азат ителә.

Мөрәҗәгать иткән көнгә мөрәҗәгать итүче мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләвенең бер өлешен компенсацияләүне ала торган булса, бу очракта

ул ата-ана түләвенең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2007 ел, 18 гыйнвар, 9 нчы карары нигезендә, «Мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләвенең бер өлешен компенсацияләү турында» гы 9 номерлы Федераль законның 2.1 пунктчаларында күрсәтелгән мәгълүматларны бирү вазыйфасыннан азат ителә.

2.2. Гариза һәм документлар почта аша җибәрелергә мөмкин. Гаризаны һәм документларны почта аша җибәрү вәкаләтле орган тарафыннан алу фактын һәм датасын расларга мөмкинлек бирүче ысул белән гамәлгә ашырыла.

2.3. Әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән документлар нигезендә вәкаләтле орган барлык кирәкле документлар белән гаризаны теркәгән көннән 10 көн эчендә компенсация билгеләү турында карар кабул итә яки аны билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итә һәм тиешле карарны мөрәҗәгать итүче күрсәткән ысул белән (хат, смс-хәбәр, электрон почта, ә мөрәҗәгать итүчеләр- Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (шәхси кабинет аша хәбәрнамә) җиткерә.

2.4. Компенсацияне билгеләүдән баш тарту өчен нигез булып тора: әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау ;

гамәлдә булу срогы чыккан документларны тапшыру (күрсәтү); закон таләпләрен бозып рәсмиләштерелгән документларны бирү.

2.5. Компенсация барлык кирәкле документлар белән гариза биргән айдан билгеләнә һәм 6 ай дәвамында түләнә.

## 3. Йомгаклау нигезләмәләре

3.1. Гариза бирүче бирелгән белешмәләрнең дөреслеге, шулай ук алар кергән документларның чынлыгы өчен җаваплы.

3.2. Вәкаләтле орган, тапшырылган документларның чынлыгына һәм дөреслегенә шик туган очракта, мөрәҗәгать итүче тарафыннан бирелгән вәкаләтләр кысаларында, өстәмә тикшерүне гамәлгә ашырырга хокуклы.

3.3. Компенсация суммасы мөрәҗәгать итүченең банк счетына күчерелә.

Сәламәтлеге торышы буенча мөмкинлекләре булмаган мөрәҗәгать итүчегә, яше, җәяүле яисә транспортта банк счетын ачарга һәм алардан файдалана алмау аркасында, компенсация түләү (китерү) элемтә оешмасы аша яисә гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә тиешле шартнамәләр (контрактлар) төзелгән башка оешмалар акчалата түләүләрне китереп торучы башка оешмалар аша гамәлгә ашырыла.

3.4. Гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә тиешле шартнамәләр (контрактлар) төзелгән банк счетларына күчерү һәм почта элемтәсе белән тәэмин итүче яисә башка төр оешма тарафыннан акчалата түләүләр китерүне гамәлгә ашыручы компенсация исәп-хисап ае дәвамында башкарыла.

3.5. Гражданнар компенсация түләүне туктату (мәгариф оешмасын алмаштыру, ата-ана хокукыннан мәхрүм итү, мөрәҗәгать итүченең үлеме) сәбәпле, мондый хәл килеп туган вакыттан бер айдан да соңга калмыйча, вәкаләтле органга хәбәр итәргә тиеш.

3.6. Түләүне туктатуга китерә торган шартлар килеп туганда, түләү тиешле шартлар туган айдан соң килүче айдан туктатыла.

3.7. Артык түләнгән компенсация суммалары, белә торып дөрес булмаган белешмәләре булган документлар тапшыру, өстәмә компенсация алу хокукына йогынты ясый торган мәгълүматларны яшерү нәтиҗәсендә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләтле органның казна счетына кертү юлы белән каплана, ә гариза бирүче кире кайтарудан баш тарткан очракта, Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри алына.

3.8. Вәкаләтле орган гаебе белән вакытында алынмаган Компенсация узган вакыт эчендә срогы чикләнмичә түләнә.

3.9. Мөрәҗәгать итүче вафат булган очракта, аңа исән чакта түләнмәгән компенсация суммалары мирас составына кертелә һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән гомуми нигезләрдә мирас итеп алына.

3.10. Компенсация бирү мәсьәләләре буенча бәхәсләр суд тәртибендә хәл ителә.